| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН СОВЕТ<br>СОРОК-САЙДАКСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КЫРЫК-САДАК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«20» августа 2020 года № 86-2

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Кырык-Садак авыл җирлеге
Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, "Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында" 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Кырык-Садак авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

I. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык-Садак авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 1-50 номерлы «Физик затлар милкенә салым турында» карарына (25.05.2015 ел, № 1-61, 09.10.2015 № 3-1, 20.06.2018 ел, № 52-1, 29.09.2018 ел, № 55-1 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 5 пунктның 4 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Салым ташламасына хокуклы зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукны раслаучы документлар тапшыра. Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан елның 1 ноябренә кадәр салым чоры булып торучы, әлеге объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым органына тапшырыла. Сайлап алынган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин.”.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http/ / buinsk. tatarstan. ru) урнаштырылырга тиеш.

Буа муниципаль районы
Кырык-Садак авыл
җирлеге башлыгы В.Ф. Шагиева